СОВЕТ СМАИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

«27 » август 2026 ел

КАРАР

№ 31

Смәел авыл җирлегенең архив фондларын булдыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Балтач районы прокуратурасының 26.06.2026 №02-08-01-2026/прдп291-26-20920011 протестын карап, Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Советының «Смәел авыл җирлеге архив фондларын формалаштыру турында» 29.09.2021 ел, № 27 карары белән расланган Смәел авыл җирлеге архив фондларын формалаштыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 өлешнең 11 пунктында «хуҗалык кенәгәләре» сүзләреннән соң «торак фондын хосусыйлаштыруга кагылышлы» сүзләрен өстәргә;

1.2. 4 бүлекнең 16 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «кулланучыларның запрослары һәм мөрәҗәгатьләре, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән Интернет челтәреннән файдаланып, электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Смәел авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Йосыпов